КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 сентябрь г.Казань № 867

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планын («юл картасы»н) раслау турында» 2017 ел, 28 февраль, 121 нче карары белән расланган «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планына («юл картасы»на) үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планын («юл картасы»н) раслау турында» 2017 ел, 28 февраль, 121 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 20 гыйнвар, 14 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан

моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планына («юл картасы»на) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Планга теркәлгән кушымтада күрсәтелгән төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) 21 төрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең 16 башкарма органы;»;

бишенче абзацта «12» саннарын «10» саннарына алыштырырга;

III бүлектәге 3 бүлекнең 3.2 нче пунктындагы 4 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2020 елның 10 сентябренә кадәр, алга таба ел саен 1 майга кадәр Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирүгә карап»;

Планга теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Россия Федерациясе субъ-ектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планына («юл картасы»на)
кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 сентябрь, 867 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре исемлеге

| Т/с | Контроль (күзәтчелек) төрләре | Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы исеме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | | |
| 1. | Кара металлар, төсле металллар калдыкларын хәзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контроле | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы |
| 2. | Алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе |
| 3. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контроле | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| 4. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, аларны карап | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | тотуга, саклап калуга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт тарафыннан саклауга төбәк дәүләт күзәтчелеге һәм һәм инвалидлар өчен мәдәни мирас объектларыннан файдалану мөмкинлеге шартларын тәэмин итүгә дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 5. | Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы |
| 6. | Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә төбәк дәүләт контроле һәм инвалидлар өчен җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә контроль | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| 7. | Төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеге | |
| 8. | тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүгә күзәтчелек һәм контроль | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| 9. | Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларыннан һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 10. | Төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |
| 11. | Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына төбәк дәүләт күзәтчелеге | Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек итү идарәсе |
| 12. | Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 13. | Транспорт чараларына техник тикшерү үткәрү өчен түләүнең иң чик күләмнәре үтәлешенә контроль | |
| 14. | Төбәк дәүләт торак күзәтчелеге | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе |
| 15. | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлегенә лицензия контроле | |
| 16. | Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеше күзәтчелеге инспекциясе |
| 17. | «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек тиүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булуы туктатылган кайбер муниципаль берәмлекләрдә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | |
| 18. | Архив эше турындагы законнарның үтәлешенә контроль | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты |
| 19. | Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы |
| 20. | Хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе |
| 21. | Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына аларны гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре исемлеге | | |
| 1. | Мәгариф өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 2. | Белем бирү эшчәнлегенә лицензия контроле | |
| 3. | Белем бирү сыйфатына федераль дәүләт контроле | |
| 4. | Федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманнарны саклау) | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы |
| 5. | Татарстан Республикасы территориясендә федераль дәүләт аучылык күзәтчелеге (федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш) | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |
| 6. | Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү мохитен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә (Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләрендә урнашкан хайваннар дөньясы объектларыннан һәм аларның яшәү мохитеннән тыш) федераль дәүләт күзәтчелеге | |
| 7. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары (исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган федераль әһәмияттәге кайбер мәдәни мирас объектларыннан тыш) торышына, аларны карап тотуга, саклап калуга, популярлаштыруга һәм дәүләт тарафыннан саклауга федераль дәүләт күзәтчелеге һәм инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларыннан һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә дәүләт контроле (күзәтчелеге) | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты |